МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.07.2019 г. Казань № под-1073/19

**Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законга туры китереп, шулай ук һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга тәңгәлләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымта итеп бирелүче административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымта итеп бирелүче административ регламентын раслау турында» 2005 елның 4 сентябрендәге под-9241/15 номерлы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2005 елның 4 сентябрендәге под-9241/15 номерлы боерыгы белән расланган Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымта итеп бирелүче административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 22 июнендәге под-1246/16 номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М.Әсәдуллинага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр Р.Т.Борһанов

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2019 елның 30.07.2019 № под-1073/19 боерыгы белән расланды

**Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү буенча гамәлләрнең (административ процедураларның) стандартын, тәртибен һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бирүчеләр булып түбәндәгеләр тора:

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга, аларны опекага (химаягә) яки сыендыручы гаиләләргә кабул итәргә теләүче Россия Федеарциясе гражданнары;

Россия Федерациясе законнары билгеләп куйган нигезләр булганда, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче – даими рәвештә Россия Федерациясеннән читтә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) – ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган

балалар хакында дәүләт мәгълүмат банкының төбәк операторы тарафыннан күрсәтелә.

«Республика уллыкка алу, опека һәм попечительлек үзәге» ДКУ (алга таба – Үзәк) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Министрлыкка ярдәм итә.

Россия Федерациясе гражданнары Министрлыкка турыдан-туры (шәхсән) мөрәҗәгать итәләр.

Әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүе башка төрле тәртипне билгеләп куймаган булса, даими рәвештә Россия Федерациясеннән читтә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз затлар Министрлыкка шәхсән яки чит ил оешмалары вәкиллекләре аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 3, 205 нче, 207 нче каб.

Үзәкнең урнашкан урыны: Казан шәһәре, Социалистическая урамы, 5 йорт.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькәчә, җомга 9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькәчә, төшке аш – 12.30 сәгатьтән 13.30 сәгатькәчә.

Үзәкнең эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, 8.30 сәгатьтән 17.00 сәгатькәчә, төшке аш 12.30 сәгатьтән 13.00 сәгатькәчә.

Керү рөхсәт һәм (яки) шәхесне раслаучы документ белән.

1.3.2. Министрлык телефоны: 5 (843) 294-95-66.

Үзәкнең телефоннары: 533-00-84, 533-00-83; 533-00-82; 533-00-79; факс: 533-00-81, 533-00-84. Казан коды: 843.

1.3.3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://www.mon.tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны алып була:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Министрлык бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматтан торган мәгълүмат стендлары ярдәмендә.

Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә язылып, стендка урнаштырыла торган мәгълүмат бу Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларына (пунктчаларына кергән) дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

2) «Интернет» челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://www.mon.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

Татарстан Республикасы хөкүмәтенең рәсми сайтыннан (www.prav.tatar.ru); Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәме белән оештырылган интернет-сайттан (www.usynovite.ru) (алга таба – Интернет-сайт);

Үзәкнең электрон почтасы (e-mail) адресы: children_kazan@mail.ru;

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать итеп.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат Министрлыкның мәгълүмат технологияләрен үстерү һәм иминлек бүлеге белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына (http://www.mon.tatar.ru) урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

Россия Федерациясенең Гаилә кодексы (алга таба – РФ Гаилә кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1996, №1, 16 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында дәүләт мәгълүмат банкы турында» 2001 елның 16 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, №17, 1643 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, №31

(I өлеш), 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе территориясендә балаларны уллыкка (кызлыкка) тапшыру һәм аларның уллыкка алучыларның гаиләләрендә яшәү һәм тәрбияләнү шартларын контрольдә тоту кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясе консуллык учреждениеләренең Россия Федерациясе гражданнары булып торучы һәм чит ил гражданнары яки гражданлыксыз затлар тарафыннан уллыкка алынган балаларны исәпкә куюы кагыйдәләрен раслау турында» 2000 елның 29 мартындагы 275 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2000, №15, 1590 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында дәүләт мәгълүмат банкы һәм аны формалаштыруны һәм файдалануны контрольдә тоту турында» 2002 елның 4 апрелендәге 217 номерлы карары (алга таба – 217 номерлы карар) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №15, 1434 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе территориясендә чит ил дәүләтләре органнары һәм оешмаларының балаларны уллыкка (кызлыкка) алу буенча эшчәнлеге һәм аның башкарылуын контрольдә тоту турында» 2006 елның 4 ноябрендәге 654 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, №46, 4801 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында дәүләт мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалануның Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 17 февралендәге № 101 боерыгы белән расланган тәртибе (алга таба – Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 101 номерлы боерыгы белән расланган тәртип) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru) 2015, 23 май, басылып чыгу номеры: 0001201503230018);

Татарстан Республикасы Гаилә кодексы (алга таба – ТР Гаилә кодексы)

(Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2009, №1, 4 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының кайбер дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 7-ТРЗ ТР законы) (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2008, №3, 212 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 елның 8 маендагы 287 номерлы карары (җыентык, 2009, № 19-20, 10797 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) (алга таба – 287 нигезләмә);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, №46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша күрсәтү күздә тотылмаган.

1.5. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр файдаланыла:

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның мәгълүмат керткәндә нигез булып торган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язу хатасы, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр

округының), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыруның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган кагыйдәләренең 34 нче пунктына туры китереп, шәһәр яки авыл җирлегендә оештырылган, территория буенча аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) төшенчәсе дәүләт хезмәте  күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 1 пунктында каралган рәсми мөрәҗәгатьне аңлата. Гаризаның формасы әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында китерелде.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты таләбе атамасы | Стандарт таләпләренең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы | Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтү | 44-ФЗ номерлы федераль закон; Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 101 номерлы боерыгы белән расланган тәртип; 287 номерлы нигезләмә |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәте күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 44-ФЗ номерлы федераль закон; Россия Мәгариф |

| | | |
|---|---|---|
| | | һәм фән министрлыгының 101 номерлы боерыгы белән расланган тәртип |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына кертү өчен нигезләр булмаганда, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;<br>баланы үз гаиләләренә тәрбиягә кабул итәргә теләүчеләр – мөрәҗәгать итүчеләр турындагы белешмәләрне балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына кертү;<br>танышып чыгу өчен, гариза бирүчегә балалар хакында төбәк мәгълүмат банкында алар турында белешмәләр булган балаларның анкеталарын бирү; бала янына бару өчен юллама бирү | 44-ФЗ номерлы федераль закон;<br>Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 101 номерлы боерыгы белән расланган тәртип |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын | Мөрәҗәгать иткән гражданнар турындагы белешмәләрне балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына кертү һәм гариза бирүчегә балалар хакында төбәк мәгълүмат банкындагы ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар турында мәгълүмат бирү документлар тапшырылган көннән башлап 8 эш көне эчендә | 44-ФЗ номерлы федераль закон;<br>Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының |

| | | |
|---|---|---|
| исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы. | башкарыла.<br>Баланы үз гаиләләренә тәрбиягә кабул итәргә теләүче гариза бирүчеләргә алар сайлаган – ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган бала янына баруга юллама бирү гариза бирүче зат бала янына барырга ризалашкан моменттан башлап 3 эш көне эчендә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору күздә тотылмаган | 101 номерлы боерыгы белән расланган тәртип |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә гариза бирүче тапшырырга тиешле кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән | 1. Россия Федерациясе гражданины белгечкә үзенең шәхесен раслаучы документны күрсәтә һәм түбәндәгеләрне тапшыра:<br>а) үзенең баланы (балаларны) үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итәргә теләве турында һәм, аның теләкләренә туры килүче балалар хакында исәптә булган белешмәләр белән таныштыруны үтенеп, бу Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән форма буенча гариза;<br>б) бу Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән форма буенча гражданин анкетасының тутырылган 1 бүлеге;<br>в) гражданинның яшәү урынында бирелгән, гражданинның уллыкка алучы, опекун (химаяче) булу мөмкинлеге турында опека һәм попечительлек органының бу Регламентка 5 нче кушымтада китерелгән форма буенча бәяләмәсе. | 44-ФЗ номерлы федераль закон;<br>Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 101 номерлы боерыгы белән расланган тәртипнең 32-33, 39-43 пп. |

| | | |
|---|---|---|
| электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 2. Россия Федерациясе гражданины баланы уллыкка алуны рәсмиләштерү моментында бер елдан артыграк срокка башка дәүләткә чыгып киткән очракта (эшкә яки башка сәбәпләр буенча), 1 пунктта күрсәтелгән документлардан тыш, түбәндәге документларны тапшыра:<br>а) баланы уллыкка (кызлыкка) алуны рәсмиләштерү моментында кайсы дәүләт территориясендә яши – шул дәүләткә барып җиткәч, шул дәүләтнең вәкаләтле органнары тарафыннан бу Регламентка 6 һәм 7 нче кушымталарда китерелгән форма буенча бирелгән: аның тормыш шартлары турында бәяләмә һәм уллыкка (кызлыкка) алынган баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын һәм аны Россия Федерациясе консуллык учреждениесендә консуллык исәбенә куюны контрольдә тоту йөкләмәсе;<br>б) чит ил оешмасының бу пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән документларны әзерләүгә вәкаләтле органнарның вәкаләтен раслаучы лицензиясе (яки чит ил дәүләте законнары билгеләгән башка документы) күчермәсе.<br>Әгәр Россия Федерациясе законнары яки Россия Федерациясенең халыкара килешүе башкача күздә тотмаса, | |

| | | |
|---|---|---|
| | документлар билгеләнгән тәртиптә легальләштерелгән, рус теленә тәрҗемә ителгән булырга тиеш һәм тәрҗемә Россия Федерациясенең Россия гражданинының яшәү урыны булып торучы дәүләттәге консуллык учреждениесендә яки дипломатлар вәкиллегендә яисә нотариус тарафыннан Россия Федерациясе территориясендә расланган булырга тиеш.<br>Карап тикшерүгә документлар аларны биргән көннән башлап бер ел дәвамында кабул ителә. Әгәр чит ил дәүләте законнары документлар гамәлдә булуның башка срогын күздә тотса, алар шул дәүләт законнары билгеләгән срок дәвамында карап тикшерелергә мөмкин.<br>3. Даими рәвештә Россия Федерациясеннән читтә яшәүче Россия Федерациясе гражданины, чит ил гражданины яки гражданлыксыз зат тапшыра:<br>а) үзенең баланы (балаларны) үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итәргә теләве турында һәм, аның теләкләренә туры килүче балалар хакында исәптә булган белешмәләр белән таныштыруны үтенеп, бу Регламентка 3 нче кушымтада китерелгән форма буенча гариза;<br>б) бу Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән форма буенча | |

| | | |
|---|---|---|
| | гражданин анкетасының тутырылган 1 бүлеге;<br>в) ул уллыкка (кызлыкка) алган баланы Россия Федерациясенең тиешле консуллык учреждениесендә, билгеләнгән тәртиптә, бу Регламентка 8 нче кушымтада китерелгән форма буенча исәпкә кую йөкләмәсе;<br>г) бу Регламентка 9 нчы кушымтада китерелгән форма буенча, уллыкка (кызлыкка) алынган баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын тикшерү өчен мөмкинлек бирү йөкләмәсе;<br>д) чит ил гражданинының шәхесен раслаучы һәм Россия Федерациясе тарафыннан шул сыйфатта танылучы документ күчермәсе;<br>е) ул кайсы дәүләт гражданины булып тора – шул дәүләтнең (даими рәвештә Россия Федерациясеннән читтә яшәүче Россия Федерациясе гражданины яки гражданлыксыз зат өчен – ул даими яшәү урынына ия булган дәүләтнең) вәкаләтле органының аның тормыш шартлары һәм уллыкка (кызлыкка) алучы булу мөмкинлеге турында бәяләмәсе. Бәяләмәгә аның гаиләсе турында фотоматериаллар кушып бирелә;<br>ж) бу Регламентка 6 нчы кушымтада китерелгән форма буенча, һәм Россия Федерациясе территориясендә чит ил дәүләтләре | |

| | | |
|---|---|---|
| | органнары һәм оешмаларының балаларны уллыкка (кызлыкка) алу буенча эшчәнлеге һәм аның башкарылуын контрольдә тоту турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 4 ноябрендәге № 654 карары белән расланган нигезләмәнең 22 нче пункты билгеләгән тәртиптә, даими рәвештә Россия Федерациясеннән читтә яшәүче Россия Федерациясе гражданины, чит ил гражданины яки гражданлыксыз затның яшәү дәүләте вәкаләтле органының уллыкка (кызлыкка) алынган баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын контрольдә тоту һәм баланың уллыкка (кызлыкка) алучы гаиләсендә яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисаплар тапшыру йөкләмәсе. Баланың уллыкка (кызлыкка) алучы гаиләсендә яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисаплар бу Регламентка 10 нчы кушымтада китерелгән форма буенча тапшырыла;<br>з) бу Регламентка 7 нче кушымтада китерелгән форма буенча, даими рәвештә Россия Федерациясеннән читтә яшәүче Россия Федерациясе гражданины, чит ил гражданины яки гражданлыксыз затның яшәү дәүләте вәкаләтле органының уллыкка (кызлыкка) алынган баланың Россия Федерациясенең консуллык учреждениесендә исәпкә куелуын, һәм Россия | |

| | | |
|---|---|---|
| | Федерациясе консуллык учреждениеләренең Россия Федерациясе гражданнары булып торучы һәм чит ил гражданнары яки гражданлыксыз затлар тарафыннан уллыкка алынган балаларны исәпкә куюының Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 29 мартындагы № 275 карары белән расланган кагыйдәләре билгеләгән срокларда үтәлүен контрольдә тоту йөкләмәсе;<br>и) уллыкка (кызлыкка) алучы булуга кандидат кайсы дәүләт гражданины булса, шул дәүләтнең вәкаләтле органының ул гражданины булган дәүләтнең законнарында бер җенестәге затлар арасында төзелгән бергәлекне никах дип тануның булмавын раслаучы документы (никахта тормаучы зат мөрәҗәгать иткән очракта бирелә);<br>к) чит ил оешмасының бу пунктның «е» – «и» пунктчаларында күрсәтелгән документларны әзерләүгә вәкаләтле органнарның вәкаләтен раслаучы лицензиясе (яки башка документы) күчермәсе;<br>л) уллыкка (кызлыкка) алучы булуга кандидатлар әзерләүне узганлык турында чит ил дәүләте законнары тарафыннан андый документларга куела торган таләпләргә туры китереп | |

| | | |
|---|---|---|
| | рәсмиләштерелгән таныклык яки башка документ күчермәсе;<br>м) чит ил дәүләте законнары тарафыннан андый документларга куела торган таләпләргә туры китереп расланган, уллыкка (кызлыкка) алучы булуга кандидатлар әзерләү шуның буенча уздырылган программа күчермәсе;<br>н) уллыкка (кызлыкка) алучы булуга кандидатлар әзерләүне узганлык турында документ биргән чит ил оешмасының гражданнарны монда күрсәтелгәнчә әзерләргә һәм тиешле документны бирергә хокукын раслаучы документ.<br>4. Чит ил гражданины баланы уллыкка алуны рәсмиләштерү моментында бер елдан артыграк срокка башка дәүләткә чыгып киткән очракта (эшкә яки башка сәбәпләр буенча), 3 пунктның «а» – «д», «и» һәм «л» – «н» пунктчаларында күрсәтелгән документлардан тыш, түбәндәге документларны тапшыра:<br>а) уллыкка (кызлыкка) алучы булу мөмкинлеге турында бәяләмә, һәм даими яшәү урыны булып торучы дәүләткә кире кайткач, шул дәүләтнең вәкаләтле органнары тарафыннан бирелгән: уллыкка (кызлыкка) алынган баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын һәм аны Россия Федерациясе консуллык учреждениесендә консуллык исәбенә куюны контрольдә тоту | |

| | | |
|---|---|---|
| | йөкләмәсе;<br>б) баланы уллыкка (кызлыкка) алуны рәсмиләштерү моментында кайсы дәүләт территориясендә яши – шул дәүләтнең вәкаләтле органнары тарафыннан бирелгән: аның тормыш шартлары турында бәяләмә һәм уллыкка (кызлыкка) алынган баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын, һәм шул дәүләткә барып җиткәч, аны Россия Федерациясе консуллык учреждениесендә консуллык исәбенә куюны контрольдә тоту йөкләмәсе;<br>в) чит ил оешмасының бу пунктның «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән документларны әзерләүгә вәкаләтле органнарның вәкаләтен раслаучы лицензиясе (яки чит ил дәүләте законнары билгеләгән башка документы) күчермәсе.<br>5. Үзе шул дәүләт гражданины булып тормаган дәүләт территориясендә даими яшәүче чит ил гражданины 3 пунктның «а»-«д», «и» пунктчаларында күрсәтелгән документлардан тыш, 3 пунктның «е»-«з» һәм «к»-«н» пунктчаларында күрсәтелгән: үзе анда даими яшәү урынына ия булган дәүләтнең вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән документларны тапшыра.<br>6. Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган, үзенең туганы булып | |

| | | |
|---|---|---|
| | торучы баланы уллыкка алырга теләүче чит ил гражданины 3-5 пунктлар күздә тоткан документлардан тыш, опека һәм попечительлек органнарына уллыкка алынучы бала белән үзенең туганлык фактын раслаучы документлар тапшыра.<br>Әгәр Россия Федерациясе законнары яки Россия Федерациясенең халыкара килешүе башкача күздә тотмаса, 3-5 пунктлар нигезендә тапшырылучы барлык документлар билгеләнгән тәртиптә легальләштерелгән, рус теленә тәрҗемә ителгән булырга тиеш һәм тәрҗемә чит ил гражданинының яшәү урыны булып торучы дәүләттә Россия Федерациясенең консуллык учреждениесендә яки дипломатлар вәкиллегендә яисә нотариус тарафыннан Россия Федерациясе территориясендә расланган булырга тиеш.<br>3 нче пунктның «а»-«г» пунктчаларында күрсәтелгән документлар карап тикшерүгә аларны төзегән көннән башлап бер ел дәвамында, ә 3 нче пунктның – «е»-«к», 4 нче пунктның «а»-«в» пунктчаларында күрсәтелгәннәре алар бирелгән көннән башлап бер ел дәвамында кабул ителә.<br>Әгәр чит ил дәүләте законнары 3 нче пунктның – «е»-«н», 4 нче пунктның «а»-«в» пунктчаларында күрсәтелгән документлар | |

| | | |
|---|---|---|
| | гамәлдә булуның башка срогын күздә тотса, алар шул дәүләт законнары билгеләгән срок дәвамында карап тикшерелергә мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган.<br>Гариза бирүче гаризасын һәм кушып бирелә торган документларны кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшыра (җибәрә) ала:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат);<br>кулга тапшырылуы турында хәбәрнамә белән почта аша заказлы хат.<br>Гариза бирүче шулай ук гариза һәм документларын квалификацияләнгән көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша | |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшыра (җибәрә) ала. | |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, гариза бирүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләрнең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | Гражданинның яшәү урынында бирелгән, гражданинның уллыкка алучы, опекун (химаяче) булу мөмкинлеге турында опека һәм попечительлек органы бәяләмәсе.<br>Документларны алу ысуллары һәм аларны тапшыру тәртибе бу Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны гариза бирүчедән таләп итү тыела. | |
| 2.7. Норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда, дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү өчен аларның килештерүләре таләп ителә торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге (килештерү дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан башкарыла) | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр күздә тотылмаган. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр:<br>әгәр гражданин балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына балаларның аның теләкләренә туры килүче белешмәләре булган яңа анкеталары керү турында ике тапкыр хәбәрнамә алып та, баланың яңа анкеталары белән танышу өчен килмәсә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр күздә тотылмаган. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торучы хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта | Гариза бирүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |

| | | |
|---|---|---|
| көтүнең максималь срогы | | |
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнне электрон рәвештә кергән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көннән соң килүче эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнарына тәңгәл рәвештә, әлеге объектларның инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе | Дәүләт хезмәте алучыларны кабул итү урыны түбәндәгеләр белән җиһазландырылган булырга тиеш:<br>һаваны җилләтү системасы;<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>мәгълүмат стендлары;<br>Татарстан Республикасының дәүләт интеграцияләнгән телекоммуникацияләр системасына тоташтырылган мәгълүмат киосклы;<br>документлар рәсмиләштерү ихтималы өчен җиһазлар.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урыныннан инвалидларның тоткарлыксыз файдалана алуы, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керүе һәм алардан чыгуы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү урынына бару максатыннан, объект буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә. | |

| | | |
|---|---|---|
| турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга һәм формалаштыруга карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән аралашулары саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең | Дәүләт хезмәте күрсәтелүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып торалар:<br>бүлек биналарның җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләрнең булуы, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеп алына торган бүлмәләрнең булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидлар өчен законнар күздә токтан уңайлы шартлар булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән билгеләнә:<br>документларны кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә биргәндә чиратлар; | |

| | | |
|---|---|---|
| ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары бозылу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең гариза бирүчеләргә әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар биргәндә, гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән аралашуы саны:<br>турыдан-туры – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәтен (дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп) дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ), КФҮнең ерактагы эш урыннары аша күрсәтү күздә тотылмаган.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны http://www.mon.tatar.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, КФҮдә алырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен | Гариза бирүчегә консультация электрон рәвештә Татарстан | |

| | | |
|---|---|---|
| электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша http://uslugi.tatar.ru адресы буенча һәм Министрлыкның рәсми сайтындагы Интернет-кабул итү бүлмәсе аша http://www.mon.tatar.ru адресы буенча бирелергә мөмкин. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт хезмәте күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедуралар үтәлешен үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) баланы үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итәргә теләп, балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына мөрәҗәгать иткәннәр, һәм балалар хакында төбәк мәгълүмат банкындагы балалар турында белешмәләр алу өчен мөрәҗәгать иткәннәр турында белешмәләрне исәпкә кую;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм җибәрү;

4) белешмәләрне балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына кертү, гариза бирүчегә балалар хакында төбәк мәгълүмат банкындагы – ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар турында мәгълүмат бирү;

5) баланы үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итәргә теләүче гариза бирүчеләргә алар сайлаган – ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган бала янына барырга юллама бирү;

6) балалар хакында төбәк мәгълүмат банкында аларның теләкләренә туры килүче бала турында белешмәләр булмаган очракта, гражданнарга булышлык күрсәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы бу Регламентка 2 нче кушымтада бирелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультация алу өчен,

Министрлыкка шәхсән үзе, телефоннан, электрон почта, Министрлыкның рәсми сайтындагы Интернет-кабул итү бүлмәсе (http://www.mon.tatar.ru) аша һәм (яки) почта аша хат белән мөрәҗәгать итә.

Министрлык хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар исемлегенең составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан да, гариза бланкын бирә һәм, зарурлык булганда, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә, техник хаталарны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик һәм арифметик хаталар) төзәтүдә.

Бу пункт билгели торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация бирү, дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар исемлегенең составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан күрсәтмәләр бирү.

3.3. Баланы үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итәргә теләп, балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына мөрәҗәгать иткәннәр, һәм балалар хакында төбәк мәгълүмат банкындагы балалар турында белешмәләр алу өчен мөрәҗәгать иткәннәр турында белешмәләрне исәпкә кую.

3.3.1. Административ процедура үтәлә башлау өчен нигез булып, гариза бирүченең Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыруы тора.

3.3.2. Тапшырылган документларны Министрлык җентекләп тикшерә: гариза бирүченең шәхесен ачыклый, шул исәптән шәхесен раслаучы документын тикшерә;

гражданин тапшырган барлык кирәкле документларның булуын һәм бу Регламентның 2.5 пункты билгеләгән таләпләргә туры килүен тикшерә.

3.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган нигезләр булган очракта, Министрлык, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, тапшырылган документларны гариза бирүчегә кире кайтара.

Процедуралар нәтиҗәсе: тапшырылган документларны карап тикшерү,

балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына кертүдән баш тартуның сәбәпләрен язмача күрсәтеп, документларны гариза бирүчегә кире кайтару.

Бу Регламентның 3.3.2-3.3.3 пунктлары билгели торган процедуралар гариза һәм документларны алган көннән башлап бер эш көне эчендә үтәлә.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм җибәрү.

3.4.1. Министрлык хезмәткәре электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, гражданинның яшәү урынында бирелгән, гражданинның уллыкка алучы, опекун (химаяче) булу мөмкинлеге турында опека һәм попечительлек органы бәяләмәсен бирүне сорап, рәсми мөрәҗәгать җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Мәгълүматлар бирүченең белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә кергән рәсми мөрәҗәгать нигезендә, соралучы документларны (мәгълүматларны) Министрлыкка тапшыра.

Бу пункт билгели торган процедуралар рәсми мөрәҗәгать кергән көннән башлап биш көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яисә баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Белешмәләрне балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына кертү, гариза бирүчегә ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган, балалар хакында төбәк мәгълүмат банкындагы балалар турында мәгълүмат бирү

3.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен бу Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаганда, Министрлык, гражданинга төбәк мәгълүмат банкында ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар турында булган мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан, әлеге гражданин турында белешмәләрне балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына кертә.

Гражданинны балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына керткәннән соң, Министрлык, танышу өчен, аның теләкләренә туры килүче балаларның анкеталарын бирә.

Бу Регламентның 3.5 пункты билгели торган процедуралар гариза һәм бу Регламентның 2.5 пункты күздә тоткан документлар алынган көннән башлап бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: гражданин турында белешмәләрне балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына кертү һәм гариза бирүчегә ата-ана кайгыртуыннан  мәхрүм калган балалар турында мәгълүмат бирү.

3.6. Баланы үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итәргә теләүче гариза бирүчеләргә алар сайлаган – ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган бала янына барырга юллама бирү.

3.6.1. Гражданин анкета мәгълүматлары белән танышкан бала янына барырга риза булган очракта, Министрлык әлеге гражданинга шул бала янына бару өчен бу Регламентка 11 нче кушымтада китерелгән форма буенча юллама бирә.

Бу Регламентның 3.6-3.6.1 пунктлары билгели торган процедуралар гариза бирүче бала янына барырга ризалашкан моменттан башлап өч эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Министрлык әлеге гражданинга шул бала янына бару өчен юллама бирә.

3.6.2. Һәр бала янына бару өчен аерым юллама бирелә.

Әгәр гражданин үз гаиләсенә тәрбиягә бердән күбрәк баланы кабул итәргә теләк белдергән һәм ир туганнар (кыз туганнар) булган һәм бер оешмада торган берничә баланы барып күрергә юллама бирүне үтенеп гариза язган булса, Министрлык күрсәтелгән барлык балаларны барып күрүгә бер юллама бирә.

Гражданинга аларны барып күрүгә юлламалар бер үк вакытта бирелә торган балаларның саны гражданинның баланы (балаларны) үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итәргә теләве турында һәм, аның теләкләренә туры килүче, балалар хакында төбәк мәгълүмат банкында булган балалар турындагы белешмәләр белән таныштыруны

үтенеп язган гаризасында күрсәтелгән балалар санынннан артык була алмый.

3.6.3. Гражданин үзе барып күргән баланы үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итүдән баш тартканда, гражданинга, аның ризалыгы белән, ул сайлаган башка баланы барып күрүгә юллама бирелә.

3.6.4. Уллыкка алу буенча чит ил оешмасы вәкиллеге хезмәткәре (алга таба – вәкиллек хезмәткәре) чит ил гражданнарының документларын тапшырган очракта, Министрлык билгеләнгән тәртиптә чит ил гражданины өчен сайлап алынган бала турындагы мәгълүматны, бу Регламентка 12 нче кушымтада китерелгән форма буенча, уллыкка алу буенча чит ил оешмасы вәкиллеге хезмәткәренә хәбәр итә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче баланы барып күрергә ризалашкан моменттан башлап 3 эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: баланы үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итәргә теләүче гариза бирүчегә ул сайлап алган, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы барып күрүгә юллама бирү.

3.7. Балалар хакында төбәк мәгълүмат банкында аларның теләкләренә туры килүче бала турында белешмәләр булмаган очракта, гражданнарга булышлык күрсәтү.

3.7.1. Балалар хакында төбәк мәгълүмат банкында ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган, гражданин аны үз гаиләсенә кабул итәргә теләгән бала турында белешмәләр булмаган очракта, ул андый баланы алга таба да эзләү үтенече белән язмача гариза бирергә хокуклы.

3.7.2. Министрлык айга кимендә бер тапкыр язмача (почта элемтәсе, факсимиль элемтә яки электрон почта ярдәмендә) гражданинга балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына балаларның гражданинның теләкләренә туры килүче белешмәләре булган яңа анкеталары керү турында, яки андый белешмәләрнең булмавы турында хәбәр итә.

Процедуралар нәтиҗәсе: балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына балаларның яңа анкеталары керү турында гражданинга хәбәр итү.

3.7.3. Әгәр гражданин балалар хакында төбәк мәгълүмат банкына

балаларның аның теләкләренә туры килүче белешмәләре булган яңа анкеталары керү турында ике тапкыр хәбәрнамә алып та, баланың яңа анкеталары белән танышу өчен килмәсә, бу гражданин өчен ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган бала (балалар) эзләү туктатып торыла һәм алга таба гражданинның язмача гаризасы нигезендә, аның турындагы белешмәләрне исәпкә алуны туктату өчен нигезләр булмау шарты белән яңадан башлана.

Процедура нәтиҗәсе: балалар хакында төбәк мәгълүмат банкыннан бала эзләүне туктатып тору.

3.7.4. Әгәр төбәк мәгълүмат банкында гражданинның теләкләренә туры килүче балалар турында белешмәләр булмаса, гражданинның язмача гаризасы нигезендә, Министрлык, бу Регламентка 13 нче кушымтада китерелгән форма буенча, балалар хакында федераль мәгълүмат банкында исәптә торучы балалар турында аның турындагы белешмәләр балалар хакында төбәк мәгълүмат банкында исәптә торган гражданин өчен белешмәләр бирүне сорап, федераль операторга мөрәҗәгать итә.

Процедура нәтиҗәсе: ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында федераль мәгълүмат банкында исәптә торган балалар турында белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.

3.7.5. Гариза бирүче турында белешмәләрне балалар хакында төбәк мәгълүмат банкында исәпкә алу түбәндәге очракларда туктатыла:

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланы гражданин үз гаиләсенә тәрбиягә кабул иткәндә. Әгәр гражданин үз гаиләсенә тәрбиягә бердән күбрәк баланы кабул итәргә теләк белдергән булса, гражданин гаиләсенә ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган, гражданинның анкетасында ничә күрсәтелгән булса, шул сандагы балаларны тапшырган очракта һәм, опека һәм попечительлек органы (чит ил дәүләтенең вәкаләтле органы) бәяләмәсенә туры китереп, гражданин үз гаиләсенә кабул итә алган балалар саныннан артмаса, гражданин турында белешмәләрне балалар хакында төбәк мәгълүмат банкында исәпкә кую туктатыла;

гражданин үзе турындагы белешмәләрне балалар хакында төбәк мәгълүмат

банкында исәпкә куюны туктату турында язмача гариза тапшырганда;

гражданинга баланы үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итәргә мөмкинлек биргән шартлар үзгәргәндә (шул исәптән гражданинның яшәү урынында бирелгән, гражданинның уллыкка алучы, опекун (химаяче) булу мөмкинлеге турында опека һәм попечительлек органы бәяләмәсенең гамәлдә булу срогы беткән очракта).

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүче турында белешмәләрне балалар хакында төбәк мәгълүмат банкында исәпкә куюны туктату.

3.8. Дәүләт хезмәтен КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыннары аша күрсәтү.

3.8.1. Дәүләт хезмәте КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелми.

3.9. Техник хаталарны төзәтү.

3.9.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документта техник хата табылган очракта, гариза бирүче Министрлыкка тапшыра:

бу Регламентка 14 нче кушымта нигезендә, форма буенча, техник хатаны төзәтү турында гариза;

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән хаталы документ;

техник хата барлыгын дәлилләүче, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гаризаны гариза бирүче (аның вәкаләтле вәкиле) шәхсән үзе, яисә почта аша, яисә электрон почта ярдәмендә, яисә Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк аша бирә.

3.9.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны терки һәм аларны Министрлыкка тапшыра.

Бу пункт билгели торган процедура гариза теркәлгән моменттан башлап бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Министрлыкка җибәрелгән гариза.

3.9.3. Министрлык документларны карап тикшерә һәм, дәүләт хезмәте

күрсәтү нәтиҗәсе булып торучы документка төзәтмәләр кертү максатыннан, бу Регламентның 3.6 пункты күздә тоткан процедураларны башкара, һәм төзәтелгән документны гариза бирүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә), алганлыгына имза куйдырып, шәхсән бирә; гариза бирүчедән (аның вәкаләтле вәкиленнән) техник хаталы документның төп нөсхәсен алып кала, яки гариза бирүче адресына почта аша (электрон почта ярдәмендә) техник хаталы документның төп нөсхәсен Министрлыкка тапшырып, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура җибәрелгән хата турында гариза бирүчедән гариза алынган моменттан башлап өч көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контроль ясау тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфатына контроль гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклауны һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итүне һәм Министрлыкның вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) һәм карарларына шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлүенә контроль формалары булып торалар:

– дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларына хокукый экспертиза уздыру;

– эш башкаруга карата билгеләнгән тәртиптә үткәрелүче тикшерүләр;

– дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле барлык мәсьәләләр дә карап тикшерелергә (комплекслы тикшерүләр) яки тикшерү гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча уздырылырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләр кылуга контроль ясау максатында, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында министрга белешмәләр бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген саклауга агымдагы контроль дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыруга җаваплы белгеч, делопроизводство хезмәте белгечләре тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге Министрлыкның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән гамәлгә кертелә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, гаепле затлар законнар нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы гариза бирүченең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшермәгән өчен җавап тота.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре, оешмалары тарафыннан контроль Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге ярдәмендә башкарыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Министрлыкка яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына судка кадәр

тәртиптә шикаять белдерүгә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

- гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы бозылганда;

- дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

- дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп ителгәндә;

- дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында күздә тотылган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

- әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

- дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

- дәүләт хезмәте күрсәтүче орган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда;

- әгәр туктатып торуның нигезләре федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары, муниципаль хокуый актлар белән күздә тотылмаса, дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып торганда;

- дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә, гариза бирүчедән дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны

кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда, юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп иткәндә.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://www.mon.tatar.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – аны теркәгән көннән башлап 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан яисә җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына карата шикаять белдерү очрагында яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерү очрагында – аны теркәгән көннән башлап 5 эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органның аларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерелә торган вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның – фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүче – юридик затның – атамасы, урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган

карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятькә аны биргән дәүләт хезмәте алучы имза сала.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлык түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Бу Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм гариза бирүченең теләге буенча, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә җибәрелүче җавапта дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк яисә оешма тарафыннан, дәүләт хезмәте күрсәткәндә килеп чыкканлыгы ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында, башкарылучы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән җайсызлыклар өчен гафу сорала, һәм гариза бирүчегә, дәүләт хезмәте алу өчен, алга таба кылырга кирәкле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта,

гариза бирүчегә җибәрелүче – бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

**Дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы һәм аны күрсәтүне контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 294-95-90 | Rafis.Burganov@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 294-96-02 | Alsu.Asadullina@tatar.ru |
| Опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге җитәкчесе | 294-95-66 | Venera.Vasileva@tatar.ru |


**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем һәм фән бүлеге җитәкчесе | 264-77-20 | Andrey.Vybornov@tatar.ru |

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта


**Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы**


**«Шартлы билгеләр»**



Дәүләт хезмәте күрсәтүнең башлануы яки тәмамлануы
Сайлап алу, карар кабул итү вазгыяте
Операция, гамәл, чара

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы




Дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать иткән гражданнар турында белешмәләрне исәпкә
Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүнең мөмкин булмавы турында хәбәр
Гариза бирүчегә ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкыннан белешмәләр бирү
Юк
Баланы барып күрергә юллама бирелә аламы?
Әйе
Баланы барып күрергә юллама бирү
Юк
Әйе
Хезмәт күрсәтүне тәмамлау өчен нигезләр бармы?
Балалар хакында төбәк мәгълүмат банкында аларның теләкләренә туры килүче балалар турында белешмәләр булмаган очракта, гражданнарга булышлык күрсәтү
Хезмәт күрсәтүнең тәмамлануы

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

_______________________________________________
(дәүләт хакиимияте органы атамасы)
_______________________________________________
_______________________________________________
_______________________________________________
(Гражданинның (-нарның) Ф.И.А.
(атасының исеме – булганда)
_______________________________________________

**Баланы (балаларны) үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итәргә теләве турында һәм, аның (аларның) теләкләренә туры килүче балалар хакында исәптә булган белешмәләр белән таныштыруны үтенеп, гражданинның (-нарның)**

**ГАРИЗАсы**

Мин (Без),____________________________________________________________________
(хәләл җефетләрнең берсенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))
Гражданлык____________________Паспорт:
серия____________№ __________________________

_____________________________________________________________________________
(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
һәм___________________________________________________________________________
(хәләл җефетләрнең икенчесенең (булганда) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) яисә икесе дә мөрәҗәгать иткән очракта)

Гражданлык___________________Паспорт:
серия__________________№ _____________________

_____________________________________________________________________________
(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

уллыкка (кызлыкка)/опекага (химаягә) алу (кирәклесенең астына сызарга) рәсмиләштерү өчен

________________баланы/балаларны (кирәкмәгәнен сызарга)
(балаларның саны)
сайлап алырга ярдәм күрсәтүне, опека һәм попечительлек органында, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында федераль/төбәк мәгълүмат банкында (кирәкмәгәнен сызарга) исәптә торучы, гражданин анкетасында күрсәтелгән теләкләргә туры килә торган балалар турында белешмәләр белән таныштыруны үтенәм (-без).

Баланы гаиләгә тәрбиягә кабул итәргә теләүче гражданин турында шәхси мәгълүматларны җыюның нигезләре, максатлары һәм файдалану тәртибе белән таныштым (-ык). Минем (безнең) шәхси мәгълүматларны ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында дәүләт мәгълүмат банкында эшкәртүгә риза. Балалар турында чыгарылма мәгълүмат җибәрү тәртибе белән таныштым (-ык).

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган баланың (балаларның) анкетасында булган, безгә бирелгән конфиденциаль мәгълүматны бары тик баланы (балаларны) минем (безнең) гаиләгә тәрбиягә тапшыру мәсьәләсен хәл итү максатларында гына кулланырга сүз бирәм (-без).

«_____»____________20___ел __________________

(имза (-лар))

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

**Баланы үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итәргә теләүче гражданин**

**АНКЕТАсы**

**1 бүлек** (гражданин тутыра)*(1)
Гражданин турында белешмәләр
(тутырылган көнгә)

______________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)
Җенесе_________ Туган көне_____________________________________________
(туган көне, ае, елы)
Туган урыны_________________________________________________________
(республика, край, өлкә, торак пункт)
Гражданлыгы___________________________________________________________
Гаилә хәле____________________________________________________
Адресы (даими теркәлгән урыны)_________________________________
(почта индексын күрсәтеп)
Адрес (яшәү урыны)____________________________________________
(почта индексын күрсәтеп)
______________________________________________________________________
Телефон (факс) номеры ________________________________________
(шәһәрара кодны күрсәтеп)
Электрон почта адресы (булганда)______________________________________
Шәхесен раслаучы документ________________________________________
(документның төре)
серия__________________номер_______________________________________________
______________________________________________________________________
(кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
Уллыкка алучы яки опекун (химаяче) булу мөмкинлеге турында бәяләмә
(тормыш шартлары һәм уллыкка алучы булу мөмкинлеге турында бәяләмә –даими рәвештә Россия Федерациясеннән читтә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз затлар өчен) әзерләнде: ______________________________________________
______________________________________________________________________
(органның атамасы)
дата_______________________номер_______________________________________;
гражданин үз гаиләсенә кабул итәргә теләгән балалар саны ________

**Гражданин үз гаиләсенә кабул итәргә теләгән бала (балалар) турында мәгълүмат** *(2)
Җенесе____________Яше ____________дан (дән) _____________ га (гә) кадәр
Сәламәтлек торышы___________________________________________________________
Тышкы кыяфәте: күз төсе____________________чәч төсе________________________
Башка төрле теләкләр______________________________________________________
Гражданин баланы үз гаиләсенә тәрбиягә кабул итәргә теләгән төбәкләр *(3)
______________________________________________________________________
«____»______________2________ел                                        гражданин имзасы

**2 бүлек** (ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында дәүләт мәгълүмат банкының тиешле операторы тутыра, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында, тиңдәшле рәвештә, төбәк һәм федераль мәгълүмат банкында) *(4)

_______________________________________________________________________

(анкета номеры) *(5)

Исәпкә кую датасы_______________________________________________

(көне, ае, елы)

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында федераль (төбәк) мәгълүмат банкының гражданин турындагы мәгълүматны документлаштырган хезмәткәре фамилиясе

_______________________________________________________________________

**Үзе сайлаган баланы күрү өчен, гражданинга ятим балалар оешмаларына барырга бирелүче юлламалар һәм ул кабул иткән карар турында мәгълүмат**

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында дәүләт мәгълүмат банкында баланың анкета номеры ______________________________________________

Юлламаны бирү көне ______________________________________________

Баланы гаиләгә кабул итәргә дигән карар турында яки, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, андый карардан баш тарту турында язып кую ____________________________________________

**Гражданин хакында белешмәләрне исәпкә куюны туктату турында мәгълүмат**

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында карар чыгару хакында документ реквизитлары (суд карары, опека һәм попечительлек органы акты, сыендыручы гаилә яки патронат гаилә төзү турында килешү)

_______________________________________________________________________

(карар чыгарган органның, килешү аның исеменнән төзелгән органның атамасы)

_______________________________________________________________________

«____» _____________2____ел   № _________

(карар чыгару көне)

Гражданин хакында белешмәләрне исәпкә куюны туктату сәбәбе__________________________

Исәпкә куюны туктату көне: «______» _____________20_____ел

______________________________

*(1) Гражданин турында шәхси характердагы белешмәләр аның шәхесен раслаучы документтагыга туры килергә тиеш.

*(2) Берничә баланы уллыкка алу теләге турында гариза биргән очракта, бүлекчә гражданин үз гаиләсенә кабул итә ала торган балалар санына тигез булган санда, һәр балага аерым тутырыла.

*(3) Гражданин төбәк операторына мөрәҗәгать итсә, төбәкләр атамасы урынына муниципаль берәмлекләр атамалары күрсәтелә.

*(4) Бары тик электрон рәвештә генә тутырыла.

*(5) Никахта торучы гражданнар анкеталарының номеры бер була.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

**Форма**

Опека һәм попечительлек
органы бланкы

**Опека һәм попечительлек органының гражданинның яшәү урынында бирелгән *(1), уллыкка алучы яки опекун (химаяче) булу мөмкинлеге турында *(2) БӘЯЛӘМӘсе**

Бер хәләл җефетнең Ф.И.А. (тулысынча, атасының исеме – булганда) ________________
________________________________________________________________________
Туган көне:__________, адрес буенча теркәлгән:__________________
________________________________________________________________________
(почта индексын күрсәтеп)
Икенче хәләл җефетнең Ф.И.А. (тулысынча, атасының исеме – булганда) (булганда яисә икесе дә мөрәҗәгать иткән очракта)____________________________________
________________________________________________________________________
Туган көне:__________, адрес буенча теркәлгән:__________________
________________________________________________________________________
(почта индексын күрсәтеп)
Адрес буенча яши (-ләр): ______________________________________________
(почта индексын күрсәтеп)
________________________________________________________________________

Гаиләнең сыйфатламасы (составы, никахның озынлыгы (икенче кат никахта булганда, алдагы никахтан туган балаларны күрсәтергә), балалар белән аралашу тәҗрибәсе, гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләр, якын туганнарның булуы һәм аларның гаиләгә бала кабул итүгә мөнәсәбәте, уллыкка алучылыкка кандидатның холык үзенчәлекләре, опекуннар (химаячеләр), сыендыручы ата-аналар, патронат тәрбиячеләр); баланы уллыкка (кызлыкка) хәләл җефетләрнең берсе алганда, икенчесенең уллыкка (кызлыкка) алуга ризалыгы булуны, опека (попечительлек) билгеләгәндә, опекун (химаяче) булырга теләк белдергән гражданин белән бергә яшәүче 10 яшькә җиткән балаларның да фикерен исәпкә алып, гаиләнең балигълык яшендәге барлык әгъзаларының баланы (балаларны) гаиләгә кабул итүгә ризалыгы булуны күрсәтергә).

________________________________________________________________________
Белеме һәм һөнәри эшчәнлеге________________________________
________________________________________________________________________
Сәламәтлек торышы сыйфатламасы (сәламәтлегенең гомуми хәле, баланы гаиләгә тәрбиягә кабул итәргә комачаулаучы авыруларның булмавы)
________________________________________________________________________
Матди хәле (мөлкәте, хезмәт хакы күләме, керемнәрнең башка төрләре, керем күләменең төбәктә билгеләп куелган яшәү минимумына чагыштырмасы)
________________________________________________________________________

Баланы (балаларны) гаиләгә тәрбиягә алу өчен мотивлар ________________________
____________________________________________________________________________

Баланың (балаларның) кандидатурасы буенча теләкләр (балаларның саны, җенесе, яше, сәламәтлеге һ.б.)
________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

Гариза бирүченең (-ләрнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)
Мөмкин булу/мөмкин булмау турында бәяләмә ___________________________________
(уллыкка алучылыкка яки опекунлыкка (попечительлеккә) *(3) кандидат (-лар) булырга)
____________________________________________________________________________

(гражданинның (-нарның) уллыкка алучылыкка яки опекунлыкка (попечительлеккә) кандидат (-лар) булу ___________________________________________________________________________
мөмкинлеге/мөмкин булмау турында карар балаларның санына һәм сәламәтлекләре торышына карата
____________________________________________________________________________

гражданинның теләкләрен исәпкә алып кабул ителә, уллыкка алучылыкка яки опекунлыкка (попечительлеккә) кандидатлыкның мөмкин булмавы турында карар кабул ителгән очракта,
____________________________________________________________________________

баш тартуның сәбәпләре күрсәтелергә тиеш *(4))

______________________ _____________ ________________________________________________
вазыйфа имза фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

М.У.

______________________________

*(1) Теркәлгән никахта торучы гражданнарга бер бәяләмә рәсмиләштерелә.
*(2) Гаилә корылышының сайлап алынган формасына бәйле рәвештә күрсәтелә. Әгәр бәяләмә берничә биттә язылган булса, битләр номерланган, тегелгән һәм бәяләмәне биргән органның мөһере белән ныгытылган булырга тиеш.
*(3) Гаилә корылышының сайлап алынган формасына бәйле рәвештә күрсәтелә.
*(4) Норматив хокукый актларның гражданинның(-нарның) уллыкка алучылыкка яки опекунлыкка (попечительлеккә) кандидат(-лар) була алмавы турында карар шуларга туры китереп кабул ителгән нормалары күрсәтелә.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
6 нчы кушымта

**Форма**

Орган (оешма) бланкы

# ЙӨКЛӘМӘ

______________________________________________________________________________
(уллыкка алынганнан соң баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын контрольдә тотарга йөкләмә бирүче орган/оешма атамасы)
Түбәндәге адрес буенча яшәүче:______________________________________________
_____________________________________________________________ тарафыннан уллыкка
(уллыкка алучылыкка кандидатларның Ф.И.А. (атасының исеме – булганда))

(кызлыкка) алынган баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын контрольдә тотарга һәм уллыкка алучылар гаиләсендә баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисаплар тапшырып торырга йөкләмә ала.
Хисаплар төзеләчәк һәм Россия Федерациясенең кайсы субъекты территориясендә уллыкка (кызлыкка) алына – шуның башкарма хакимият органына турыдан-туры/чит ил оешмасының уллыкка алу буенча вәкиллеге аша * тапшырылачак.

___________________________________________________________________________
(гражданнарга уллыкка алуда ярдәм күрсәтәчәк чит ил оешмасы атамасы

___________________________________________________________________________
һәм аның адресы)
___________________________________________________________________________

Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китереп **:
баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын беренче тикшерү уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 2 ай үткәннән соң уздырыла, баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисап уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 4 нче ай тәмамланганнан соңга калмыйча тапшырыла;
баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын икенче тикшерү уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 5 ай үткәннән соң уздырыла, баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисап уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 7 нче ай тәмамланганнан соңга калмыйча тапшырыла;
баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын өченче тикшерү уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 11 ай үткәннән соң уздырыла, баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисап уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 13 нче ай тәмамланганнан соңга калмыйча тапшырыла;
баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын дүртенче тикшерү уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 23 ай үткәннән соң уздырыла, баланың яшәү һәм

тәрбияләнү шартлары турында хисап уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 25 нче ай тәмамланганнан соңга калмыйча тапшырыла;
баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын бишенче тикшерү уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 35 ай үткәннән соң уздырыла, баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисап уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 37 нче ай тәмамланганнан соңга калмыйча тапшырыла.
Уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 3 ел үткәннән соң һәм ул балигълык яшенә җиткәнгә кадәр баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын тикшерү баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында аннан алдагы хисап төзелгән көннән башлап 23 ай үткәннән соң уздырыла. Баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисап аннан алдагы хисап төзелгән көннән башлап 25 нче ай тәмамланганнан соңга калмыйча тапшырыла.
Хисаплар тиешле чит ил дәүләтенең дәүләт (рәсми) телендә тапшырыла.
Әгәр Россия Федерациясе законнары яки Россия Федерациясенең халыкара килешүе башкача күз алдында тотмаса, тапшырылучы хисаплар билгеләнгән тәртиптә легальләштерелгән, шулай ук рус теленә тәрҗемә ителгән булырга тиеш. Бу вакытта тәрҗемә уллыкка алучыларның яшәү урыны булып торучы дәүләттә Россия Федерациясенең консуллык учреждениесендә яки дипломатлар вәкиллегендә яисә нотариус тарафыннан Россия Федерациясе территориясендә раслана.
Хисапларга кушып, фотоматериаллар бирелергә тиеш.
Тапшырылган хисапларда чистартулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка төзәтүләр, шулай ук аларның булуы эчтәлекне дөрес аңларга комачаулый торган җитди зарарланулар булмаска тиеш.

______________ _______________ ______________________________________
(вазыйфа) (имза) (И. Фамилия)

М.У.

---

* Россия Федерациясе территориясендә балаларны уллыкка (кызлыкка) алу буенча эшчәнлек алып баруга тиешле рөхсәтләр алган: чит ил дәүләтенең Россия Федерациясе территориясендә уллыкка (кызлыкка) алу буенча органы яки оешмасының вәкиллеге яки чит илнең коммерцияле булмаган, хөкүмәтнеке булмаган оешмасы вәкиллеге булышлыгы белән уллыкка алу очрагында гына күрсәтелә.
** Россия Федерациясе территориясендә чит ил дәүләтләре органнары һәм оешмаларының балаларны уллыкка (кызлыкка) алу буенча эшчәнлеге һәм аның башкарылуын контрольдә тоту турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 4 ноябрендәге № 654 карары белән расланган нигезләмәнең 22 нче пункты (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 46, 4801 ст., 2013, № 35, 4511 ст.).

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
7 нче кушымта

**Форма**

Орган (оешма) бланкы

ЙӨКЛӘМӘ

_______________________________________________________________________________
(уллыкка алынган баланың Россия Федерациясенең консуллык учреждениесендә исәпкә куелуын контрольдә тотарга йөкләмә бирүче орган/оешма атамасы)

түбәндәге адрес буенча яшәүче:_______________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
(уллыкка алучылыкка кандидатларның Ф.И.А. (атасының исеме – булганда))

тарафыннан Россия Федерациясендә уллыкка алынган баланың
түбәндәге адрес буенча урнашкан: _____________________________________________
(консуллык учреждениесе адресы)

консуллык учреждениесендә ____________________________________________________
(консуллык учреждениесе атамасы)
исәпкә куелуын контрольдә тотарга йөкләмә ала.

______________ ______________ ________________________________
(вазыйфа) (имза) (И. Фамилия)

М.У.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
8 нче кушымта

**Форма**

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында дәүләт мәгълүмат банкының төбәк операторына

___________________________________дан
(гражданинның (-нарның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))
______________________________________

______________________________________

# ЙӨКЛӘМӘ

Мин (Без), ______________________________________________________________
(Ф.И.А. (атасының исеме – булганда), шәхесне раслаучы документ (-лар) реквизитлары)
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________,
түбәндәге адрес буенча яшәүче (-ләр): _________________________________________
_________________________________________________________________________,
минем (безнең) тарафтан уллыкка алынган бала мин (без) шуның территориясендә яши торган дәүләткә килеп кергән көннән башлап 3 айлык срокта аны

түбәндәге адрес буенча урнашкан:______________________________________________
(консуллык учреждениесе адресы)

консуллык учреждениесендә: __________________________________________________
(Россия МИД/гражданин яши торган консуллык
_________________________________________________________________________
территориясендәге консуллык учреждениесе атамасы)
_________________________________________________________________________

исәпкә куярга йөкләмә алам (-быз).

Уллыкка алынган баланың яшәү урыны үзгәргәндә, бу хакта әлеге консуллык учреждениесенә хәбәр итәргә һәм баланы яңа яшәү урынындагы Россия Федерациясе консуллык учреждениесендә исәпкә куярга йөкләмә алам (-быз).

«_____»_______________20___ел                    ______________________
(имза (-лар))

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
9 нчы кушымта

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында дәүләт мәгълүмат банкының төбәк операторына

___________________________________дан
(гражданинның (-нарның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))
_____________________________________
_____________________________________

Мин (Без), _______________________________________________________________
(Ф.И.А. (атасының исеме – булганда), шәхесне раслаучы документ (-лар) реквизитлары)
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________,
түбәндәге адрес буенча яшәүче (-ләр): ________________________________________
__________________________________________________________________________,

минем (безнең) яшәгән урындагы вәкаләтле органнарга минем (безнең) тарафтан уллыкка алынган баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын тикшерергә мөмкинлек тудырырга йөкләмә алам (-быз).

Яшәү урыны үзгәргәндә, бу хакта минем (безнең) тарафтан уллыкка алынган баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын контрольдә тотарга йөкләмә биргән вәкаләтле органга хәбәр итәргә, шулай ук минем (безнең) яңа яшәү урынындагы вәкаләтле органга минем (безнең) тарафтан уллыкка алынган баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын тикшерергә мөмкинлек тудырырга йөкләмә алам (-быз).

Мин (Без) Россия Федерациясе законнарына туры китереп, түбәндәгеләрдән хәбәрдар һәм аларга риза:

баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын беренче тикшерү уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 2 ай үткәннән соң уздырыла, баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисап уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 4 нче ай тәмамланганнан соңга калмыйча тапшырыла;

баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын икенче тикшерү уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 5 ай үткәннән соң уздырыла, баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисап уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 7 нче ай тәмамланганнан соңга калмыйча тапшырыла;

баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын өченче тикшерү уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 11 ай үткәннән соң уздырыла, баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисап уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 13 нче ай тәмамланганнан соңга калмыйча тапшырыла;

баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын дүртенче тикшерү уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 23 ай үткәннән соң уздырыла, баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисап уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 25 нче ай тәмамланганнан соңга калмыйча тапшырыла;
баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын бишенче тикшерү уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 35 ай үткәннән соң уздырыла, баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисап уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 37 нче ай тәмамланганнан соңга калмыйча тапшырыла.
Уллыкка алу турында суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 3 ел үткәннән соң һәм ул балигълык яшенә җиткәнгә кадәр баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартларын тикшерү баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында аннан алдагы хисап төзелгән көннән башлап 23 ай үткәннән соң уздырыла. Баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисап аннан алдагы хисап төзелгән көннән башлап 25 нче ай тәмамланганнан соңга калмыйча тапшырыла.

«______»___________20___ел                    ___________________

(имза (-лар))

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
10 нчы кушымта

**Форма**

Хисапны әзерләгән решма бланкы.
Хисап төзү көне

**Уллыкка (кызлыкка) алучының гаиләсендә баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында**
**ХИСАП**

Уллыкка (кызлыкка) алынганнан соң баланың Ф.И.А. (атасының исеме – булганда) __________
______________________________________________________________________________
Баланың җенесе _______________________________________________________________
Уллыкка (кызлыкка) алынганнан соң туган көне ______________________________________
Уллыкка (кызлыкка) алыну көне _________________________________________________
Уллыкка (кызлыкка) алу турында суд карары законлы көченә кергән көн _________________
Уллыкка (кызлыкка) алынганга кадәр баланың Ф.И.А. (атасының исеме – булганда) _________
______________________________________________________________________________

Уллыкка (кызлыкка) алынганга кадәр туган көне _____________________________________
Уллыкка (кызлыкка) алынганга кадәр яшәү урыны (Россия Федерациясе субъекты) __________
Уллыкка алучыларның Ф.И.А. (атасының исеме – булганда), аларның яше _________________
______________________________________________________________________________
Баланың һәм уллыкка алучыларның яшәү адресы, телефон ______________________________
Уллыкка алучыларның эш урыны, адрес, телефон ______________________________________
Тикшерү уздырган вазыйфаи затның Ф.И.А. (атасының исеме – булганда)
___________________
______________________________________________________________________________
Тикшерүне уздыру көне ________________________________________________________
Аннан алдагы тикшерүне уздыру көне, кем уздырган __________________________________
Киләсе тикшерүне уздыру көне __________________________________________________

**1. Баланың ихтыяҗларын тәэмин итү.**
(Төп ихтыяҗларына һәм тикшерү моментында аларның ничек канәгатьләндерелүенә характеристика бирергә, нинди чара күрергә кирәклеген, моннан алдагы тикшерү барышында ниятләнгәннәрдән нәрсәнең эшләнгәнен (эшләнмәгәнен) күрсәтергә).
Сәламәтлек: физик үсеше – буе, авырлыгы, проблемалары, күрелгән чаралар, ел саен медицина тикшерүе узуы, прививкалары.

Белем алуы: уңышлары, проблемалары, аларның үз яшенә туры килүе, белем бирү программаларын үзләштерү формасы, мәгариф оешмасының тибы, өстәмә белем алуы (баланың нинди өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларына йөрүен күрсәтергә; баланың яшенә бәйле рәвештә күрсәтелә).
Баланың сәләтләре үсешен тәэмин итү: баланың уйный алу, түгәрәкләргә йөрү, спорт белән шөгыльләнү мөмкинлеге.
Тышкы кыяфәте һәм социаль таләпләргә яраклашуы: киеменең яшенә, җенесенә, мәдәниятккә, дингә туры килүе, шәхси гигиенасы, баланың төрле шартларда үз-үзен тәртипле тотуы, уллыкка алучыларның киңәшләрен кабул итүе.
Үз-үзенә хезмәт күрсәтү күнекмәләре: киенә, мөстәкыйль ашый, социаль һәм көнкүрештәге проблемаларны хәл итә белүе.

**2. Уллыкка алучыларның баланың ихтыяҗларын тәэмин итәргә сәләтле булуы.**

Төп карау: баланың төп ихтыяҗларын канәгатьләндерү: ризык, торак, гигиена, кием белән тәэмин итү, медицина ярдәме күрсәтү.
Баланың яшенә тәңгәл рәвештә аның иминлеген тәэмин итү (көнкүрештәге куркыныч предметларга кулы җитмәслек булу).
Уллыкка алучылар үзләренең яратуын ничек күрсәтә, бала күңел җылысын тойсын өчен кирәкле якын күрү бармы.

**3. Гаилә һәм тирәлек факторлары.**

Гаилә тарихы: уллыкка алучылар гаиләсе тарихының хәзерге вакытта бала тормышына йогынтысы – өйдә кемнәр яши һәм балага бу ничек тәэсир итә, хәзерге вакытта һәм элегрәк гаилә составындагы үзгәрешләр, уллыкка алучыларның гражданлык статусы яки гаилә хәле үзгәрү турында, гаиләдәге кыйммәтләр һәм традицияләр, уллыкка алучыларның туганнары белән һәм үзара мөнәсәбәтләре рәвеше, ул мөнәсәбәтләрнең балага йогынтысы.
Гаиләнең социаль элемтәләре: күршеләр, танышлар белән, баланың үз яшьтәшләре, педагоглар, тәрбиячеләр белән бәйләнеше.
Торак.
Гаилә яшәешенең торак һәм көнкүреш шартлары:
гомуми һәм яшәргә яраклы мәйданы; торакның яшәү өчен билгеләнгәнлеге һәм уңайлыклары булу; санитария-гигиена ягыннан торышы – яхшы, канәгатьләнерлек, канәгатьләнмәслек; яшәүнең көнкүреш һәм финанс шартлары турында өстәмә мәгълүматлар.
Баланың аерым бүлмәсе, караваты, уйнар өчен, шөгыльләнер өчен урыны, уенчыклары, китаплары, көн һәм туклану режимы булу.
Эш: кем эшли, эшнең булуы яки булмавы, эш режимы, эштәге үзгәрешләр һәм боларның балага ничек йогынты ясавы.
Керем: җитәрлекме-юкмы, бу балага ничек йогынты ясый, бала барлык кирәкле әйберләр белән тәэмин ителгәнме (кием-салымы, аяк киемнәре, йомшак инвентаре, уенчыклары, уку-язу әсбаплары җитәме), махсус түгәрәкләр, мәктәпләр өчен түләү.
Яшәү урынындагы ресурслар: мәгариф оешмаларының, мәдәният оешмаларының, медицина оешмаларының якын булуы.
Нәтиҗәләр:
1. Нәрсәне тәэмин итү таләп ителүен (3 бүлек буенча: баланың ихтыяҗлары, уллыкка алучыларның баланың ихтыяҗларын тәэмин итәргә сәләтле булуы, гаилә һәм тирәлек факторлары) һәм уллыкка алучылардан моның өчен нәрсә эшләү (үзгәртү) таләп ителүен билгеләргә.
2. Гаиләгә һәм балага өстәмә ярдәм таләп ителәме һәм аны кем бирәчәк.

Нәтиҗәләр: уллыкка алуның уңышлылыгын бәяләү: ______________________________.

___________________________________
(Хисапны төзегән затның Ф.И.А.
(атасының исеме – булганда), имзасы)

М.У.

Раслыйм

_________________________________________ ___________ _____________________________________

(опека һәм попечительлек органы җитәкчесе) (имза) (Ф.И.А.( атасының исеме – булганда))

М.У.

__________________________________

**Искәрмәләр:**

1. Хисапны төзегәндә, конфиденциальлекне саклау зарури.

2. Чит ил гражданнары, даими рәвештә Россия Федерациясеннән читтә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары, гражданлыксыз затлар Россия Федерацияясе гражданины булып торучы баланы уллыкка алганда, хисап үз өстенә тиешле йөкләмәләр алган вәкаләтле орган бланкында әзерләнә. Хисапка кушып, баланың хисап төзелгән моменттагы фоторәсемнәре бирелә.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
11 нче кушымта

Юллама биргән орган бланкы
___________________________
(адрес һәм телефон)
_____________ № ___________

__________________________________________
(медицина оешмасының, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен булган оешманың атамасы)
директоры (баш табибы)
_______________________________________ га
(оешма җитәкчесенең Ф.И.А. (атасының исеме – булганда))

**Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган бала янына барырга**
**ЮЛЛАМА**

Бирелде: _______________________________________________________________ га,
(гражданнарның Ф.И.О. (атасының исеме – булганда))
________________________________________________________________ка кандидатларга,
(гаилә корылышы формасына бәйле рәвештә)
_______________________________________________________ гражданнарына
(кандидатлар аның гражданнары булган дәүләт атамасы)
уллыкка (кызлыкка) яки опекага (химаягә) алуны (кирәклесенең астына сызарга) рәсмиләштерү өчен
бала _____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________ янына барырга.
(баланың Ф.И.А. (атасының исеме – булганда), туган елы)

___________________________ ______________ ____________________________________
(юллама биргән орган җитәкчесе) (имза) (Ф.И.А. (атасының исеме – булганда))

М.У.

Кабул ителгән карар турында мәгълүматлар________________________________________________.
(ризалык/баш тарту (сәбәпләрен күрсәтеп)

Дата__________________________________________
(уллыкка алучылыкка кандидатларның имзалары)

________________________________

**Искәрмә.** Юллама шәхесне раслаучы документ күрсәткәннән соң бирелә һәм ун эш көне дәвамында гамәлдә була.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
12 нче кушымта

**Форма**

## Гаиләгә тәрбиягә тапшырылырга тиешле бала турында
## МӘГЪЛҮМАТ

Исеме__________________________________Җенесе_______________________________________
Туган ае, елы______________________________________________________________
Билгеләре__________________________________________________________________________
(күз төсе, чәч төсе)
Холык үзенчәлекләре____________________________________________________________
Күз төсе _____________________Чәч төсе _____________________________________
Этник чыгышы________________________________________________________
Сәламәтлеге торышы ______________________________________________________________
Физик үсеше _____________________________________________________________
Акыл үсеше ______________________________________________________________
Инвалидлыгы булу (булмау)_____________________________________________

Балигъ булмаган ир туганнары һәм кыз туганнары турында белешмәләр:
Исеме_____________________туган елы____________________________________________
Мәгълүматка кушып, баланың фоторәсеме (яки аның электрон күчермәсе) бирелә.
Гаилә корылышының ихтимал формалары_________________________________________

_________________ ________________ ____________________________________________
(вазыйфа) (имза) (фамилия, исем, атасының исеме (булганда))

М.У.

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
13 нче кушымта

**Форма**

Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган
балалар турында дәүләт мәгълүмат
банкының төбәк операторы вазыйфалары
йөкләнгән Россия Федерациясе субъектының
башкарма хакимият органы бланкы

**Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында федераль мәгълүмат банкында исәптә торучы балалар турында белешмәләр бирү турында**

**РӘСМИ МӨРӘҖӘГАТЬ**

Уллыкка алучылыкка, опекунлыкка (попечительлеккә) (кирәкмәгәнен сызарга) ирле-хатынлы кандидатлар:_______________________________________________________________

_______________________________________________________________________

(фамилия, исем, атасының исеме (булганда))

_______________________________________________________________________

(шәхесне раслаучы документ, аның сериясе һәм номеры)

_______________________________________________________________________

(гражданинның (ир белән хатынның икесенең дә) анкета номеры)

өчен балалар хакында федераль мәгълүмат банкында исәптә торучы һәм түбәндәге теләкләргә туры килүче балалар турында белешмәләр бирүне үтенәбез.

Җенесе_______Яше: ___________дан________га кадәр
Сәламәтлеге торышы_______________________________________________________
Тышкы кыяфәте: күз төсе_________________чәч төсе__________________________,
_________________________________________________________________ да яшәүче
(Россия Федерациясенең гражданнар бара алырлык субъектын күрсәтергә)

Башка таләпләр___________________________________________________________

Баланың www.usynovite.ru сайтындагы анкетасының Web-номеры:

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган
балалар турында дәүләт мәгълүмат
банкының төбәк операторы вазыйфалары
йөкләнгән Россия Федерациясе субъектының
башкарма хакимият органы
җитәкчесе _______________ ________________________________
(имза) (Ф.И.А. (атасының исеме – булганда))

Ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар хакында төбәк мәгълүмат банкын формалаштыру, алып бару һәм файдалану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
14 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрына
Кемнән ______________________
______________________________

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
___________________________________________________________________________
(хатаның төре)
Язылган: _________________________________________________________________
Дөрес белешмәләр: ____________________________________________________
Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне үтенәм.
Түбәндәге документларны кушып бирәм:
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
Телефон: ___________________________ E-mail: _______________________________

Дата _______________ Имза_________________/_____________________________

Эш өчен кирәкле язмалар
Гариза керде:
Дата:
керү №:
Гаризаны кабул иткән затның Ф.И.А. һәм имзасы